**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

2022 елның 23 гыйнвары.

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге башлыгы инициативасы белән үткәрелде, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге башлыгының 2021 елның 29 ноябрендәге 94-РС номерлы карары белән билгеләнде.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге Уставы нигезендә халык алдында тыңлаулар билгеләү турында 2021 елның 29 ноябрендәге 94-РС номерлы карары басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2021 елның 6 декабрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;
2. 2021 елның 1 декабрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Камская новь» газетасында;
3. 2021 елның 6 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру сроклары һәм урыны, катнашучылар җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 6 декабрендә 5970/исх номерлы белдерүе белән хәбәр ителделәр.

Гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр 2021 елның 6 декабрендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2021 елның 8 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлегенең рәсми сайтында;
2. 2021 елның 8 декабрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Камская новь» газетасында (мәгълүмат хәбәрләрен бастырып чыгару юлы белән);
3. 2021 елның 8 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Гавами тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Башкарма комитеты.

Рәислек итүче: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе рәисе урынбасары- Карсалов Алексей Петрович.

Ачык тыңлаулар секретаре: - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе секретаре- Прокофьева Любовь Ивановна.

Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә 2022 елның«21»гыйнварындагы беркетмә нигезендә төзелде.

Ачык тыңлауларда 8 кеше катнашты.

Ачык тыңлауларда катнашучылардан проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кермәде.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре:

1. Халык тыңлауларын үткән дип танырга;

**2.** Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын, 2022 елның«21»гыйнварындагы гавами тыңлаулар беркетмәсен, шулай ук әлеге бәяләмәне, проектны йомгаклап раслау өчен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә.

Ачык тыңлаулар рәисе ___________________________ Карсалов А.П.

Ачык тыңлаулар секретаре __________________________ Прокофьева Л.И.